# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# САРМАШ-БАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

**№ 103** **28.05.2018**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 29 ноябрендәге 61 номерлы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 29 ноябрендәге 61 номерлы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге карары (2015 елның 02 мартындагы 124 номерлы карар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәршләрне кертергә:

1.1. 27 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Даими комиссияләргә, шулай ук Совет депутатларына контроль-хисап палатасы бәяләмәсе белән җирлек бюджеты турында карар проекты җибәрелгәннән соң ике атна эчендә карар проекты Совет каравына чыгарыла. Җирлек бюджеты турындагы карар бер укылышта, ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә»;

1.2. 17 пунктның 2 пунктчасының 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрендә»;

1.3. 24 пунктның 1 пунктчасының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында http://zainsk.tatarstan.ru/rus/sarmashbashskoe.htm урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольне үз өстемдә калдырам.

**Сармаш-Баш авыл җирлеге башлыгы урынбасары** **Арсланова Н.Н.**